Әлмәт шәһәре Башлыгы
карары

20 май 2020 ел № 14

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар уздыру турындагы 2008 елның 31 октябрендәге 63 нче номерлы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер, Кама-Исмәгыйль авыл җирлекләре, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге, «Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территорияләре буйлап узучы «Төен-Исмәгыйль ВЛ 110 кВ реконструкциясе» объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру срогы - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.

3. Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39 й. адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының зур утырышлар залында 2020 елның 5 июнендә 11.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт адресы буенча урнашкан Башкарма комитетта территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр 2020 елның 5 июненә кадәр кабул ителә.

5. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына (Косарев Д.В.) үткәрү, беркетмә әзерләү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бирү эшен оештырырга.

6. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Ф. Вәлиевка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов